Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советы

Шигали авыл җирлеге Башлыгы
# КАРАРЫ

«14» апрель, 2026 ел № 8

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең Яңа Шигали авылы территориясен планлаштыру проектын раслау турында гавами тыңлаулар үткәрү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 6 номерлы карары белән расланган нигезләмә (2017 елның 14 декабрендәге 19 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 11, 2019 елның 2 октябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 61 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләре белән) нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге үзәге Яңа Шигали авылы территориясен планлаштыру проекты.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шиһали авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 8 маеннан да соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы Л.Р. Хәбибуллин

СОВЕТ ШИГАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ